КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 26 март г.Казань № 173

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карары белән расланган «Безнең иң яхшы методист» гранты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, 1078 нче; 2022 ел, 29 июнь, 613 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 956 нчы; 2023 ел, 3 февраль, 92 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче; 2023 ел, 28 август, 1033 нче; 2023 ел, 25 сентябрь, 1184 нче; 2024 ел, 2 декабрь, 1087 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Безнең иң яхшы методист» гранты турындагы нигезләмәгә, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Грант бер тапкыр 172 414 сум күләмендә бирелә һәм грант алучының Россия кредит оешмасында ачылган счетына күчерелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин